КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 25 май г.Казань № 362

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларының Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гражданнарга мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына керми торган ашыгыч медицина ярдәме, беренчел медицина-санитария ярдәме (гражданнарга төп авыруы (хәле) буенча диспансер күзәтүен кертеп) күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус социаль түләүләрне гамәлгә ашыру турында» 2023 ел, 03 апрель, 395 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларының Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гражданнарга мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына керми торган ашыгыч медицина ярдәме, беренчел медицина-санитария ярдәме (гражданнарга төп авыруы (хәле) буенча диспансер күзәтүен кертеп) күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус социаль түләүләрне гамәлгә ашыру турында» 2023 ел, 03 апрель, 395 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 09 ноябрь, 1446 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

«а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) беркетелгән халыкка территориаль-участок принцибы буенча беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүче, шулай ук гражданнарның төп авыруы (хәле) буенча диспансер күзәтүен гамәлгә ашыручы медицина оешмаларында эшләүче гражданнар авырулары (хәлләре) яисә профилактика максаты белән, тикшеренүләр уздыруны да кертеп, мөрәҗәгать итә торган табибларга һәм югары (медицина булмаган) белемле медицина хезмәткәрләренә:

50 меңгә кадәр халкы булган торак пунктларда урнашкан медицина оешмалары яисә аларның структур бүлекчәләре хезмәткәрләре булып торучы – 50 000,0 сум;

50 меңнән 100 меңгә кадәр халкы булган торак пунктларда урнашкан медицина оешмалары яисә аларның структур бүлекчәләре хезмәткәрләре булып торучы – 29 000,0 сум;

100 меңнән артык халкы булган торак пунктларда урнашкан медицина оешмалары яисә аларның структур бүлекчәләре хезмәткәрләре булып торучы – 14 500,0 сум;

үзәк район, район һәм участок хастаханәләренең табибларына һәм югары белемле медицина (медицина булмаган) хезмәткәрләренә, әлеге пунктчаның беренче абзацында һәм әлеге пунктның «б» пунктчасында күрсәтелгән медицина хезмәткәрләреннән тыш:

50 меңгә кадәр халкы булган торак пунктларда урнашкан медицина оешмалары яисә аларның структур бүлекчәләре хезмәткәрләре булып торучы – 50 000,0 сум;

50 меңнән 100 меңгә кадәр халкы булган торак пунктларда урнашкан медицина оешмалары яисә аларның структур бүлекчәләре хезмәткәрләре булып торучы – 29 000,0 сум;

100 меңнән артык халкы булган торак пунктларда урнашкан медицина оешмалары яисә аларның структур бүлекчәләре хезмәткәрләре булып торучы – 18 500,0 сум;

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) әлеге пунктның «а» пунктчасында күрсәтелгән табиблар белән эшләүче, шулай ук территориаль участок принцибы буенча беркетелгән халыкка авыруына (хәленә) бәйле рәвештә яки профилактика максаты (тикшерүләр үткәрүне кертеп) белән беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүче һәм (яки) гражданнарга төп авыруы (хәле) буенча диспансер күзәтүен гамәлгә ашыручы урта медицина персоналына:

50 меңгә кадәр халкы булган торак пунктларда урнашкан медицина оешмалары яисә аларның структур бүлекчәләре хезмәткәрләре булып торучы – 30 000,0 сум;

50 меңнән 100 меңгә кадәр халкы булган торак пунктларда урнашкан медицина оешмалары яисә аларның структур бүлекчәләре хезмәткәрләре булып торучы – 13 000,0 сум;

100 меңнән артык халкы булган торак пунктларда урнашкан медицина оешмалары яисә аларның структур бүлекчәләре хезмәткәрләре булып торучы – 6 500,0 сум;

үзәк район, район һәм участок хастаханәләренең урта медицина персоналына, әлеге пунктчаның беренче абзацында һәм әлеге пунктның «г» пунктчасында күрсәтелгән урта медицина белеме булган белгечләрдән тыш:

50 меңгә кадәр халкы булган торак пунктларда урнашкан медицина оешмалары яисә аларның структур бүлекчәләре хезмәткәрләре булып торучы – 30 000,0 сум;

50 меңнән 100 меңгә кадәр халкы булган торак пунктларда урнашкан медицина оешмалары яисә аларның структур бүлекчәләре хезмәткәрләре булып торучы – 13 000,0 сум;

100 меңнән артык халкы булган торак пунктларда урнашкан медицина оешмалары яисә аларның структур бүлекчәләре хезмәткәрләре булып торучы – 8 000,0 сум;»;

«ж» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ж) табибларга һәм өлкәннәргә күчмә патронаж паллиатив медицина ярдәме бүлекчәләренең югары белемле (медицина булмаган) медицина хезмәткәрләренә - 11 500,0 сум;

табибларга һәм балаларга күчмә патронаж паллиатив медицина ярдәме бүлекчәләренең югары белемле (медицина булмаган) медицина хезмәткәрләренә - 11 500,0 сум;

өлкәннәргә күчмә патронаж паллиатив медицина ярдәме бүлекчәләренең урта медицина персоналына - 7 000,0 сум;

балаларга күчмә патронаж паллиатив медицина ярдәме бүлекчәләренең урта медицина персоналына - 7 000,0 сум.».

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин